ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вакытлы басмасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 23 маендагы 2924-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вакытлы басмасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 23 маендагы 2924-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына (2016 елның 26 октябрендәге 1425-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2022 елның 29 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

2) «Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вакытлы басмасы турында нигезләмәдә:

а) 3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә» сүзләрен «Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта «Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2022 елның 29 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 пунктта «Татарстан Республикасы законнарын, Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, башка актларны рәсми бастырып чыгару» сүзләрен «Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, башка актларны бастырып чыгару» сүзләренә алмаштырырга;

г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Басма дүрт бүлектән тора:

1) беренче бүлектә Дәүләт Советы карарлары бастырыла;

2) икенче бүлектә Дәүләт Советы Президиумы карарлары бастырыла;

3) өченче бүлектә Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәләре бастырыла (Дәүләт Советы Рәисенең яисә Дәүләт Советы Секретаренең тиешле карарлары нигезендә);

4) дүртенче бүлектә Дәүләт Советы йә аның Президиумы карарларына шикаять белдерү турындагы эшләр буенча суд карарлары яисә законнар нигезендә бастырып чыгару мәҗбүри булган мондый карарлар хакында белдерүләр бастырыла.»;

д) 14 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) басманың статусы – Дәүләт Советы рәсми басмасы;».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 3 июне
№ 74-VII ДСП